**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.10.2018 № 880

2016 елның 19 августындагы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны даими йөртүне оештыру” турындагы нигезләмәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 544 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими йөртүне оештыру турындагы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законны гамәлгә ашыру турында”гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2016 елның 19 августындагы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны даими йөртүне оештыру” турындагы нигезләмәне (алга таба - нигезләмә) раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 544 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирларны һәм багаж йөртүне оештыру турында”гы нигезләмәгә (2018 елның 24 апрелендәге редакциядә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 13.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“13.5. Башкарма комитет даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча түбәндәге шартларның берсе генә булса да килеп чыккан очракта, пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турындагы таныклыкның гамәлдә булуын туктату турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итә:

- 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими йөртүне оештыру турындагы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законның 37 маддәсенең 2 өлешендә каралган срокларда юридик зат, индивидуаль эшкуар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучы, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында бер ел дәвамында квартал саен хисапларны берничә тапкыр тапшырмау;

- бер ел дәвамында әлеге таныклык бирелгән юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсен генә булса да, таныклыкта күрсәтелгән ташуның кагыйдәләрен бозган өчен административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 11.33 маддәсенең 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән административ җаваплылыкка тарту;

- гади ширкәт шартнамәсен өзү (әлеге таныклык гади ширкәт килешүендә катнашучыларга бирелгән очракта);

- машина йөртүче гаебе белән кеше сәламәтлегенә авыр зыян салган яисә кеше үлеменә китергән юл-транспорт һәлакәте;

- 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуны оештыру турындагы һәм Россия Федерациясенең аерым законы актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7.1 маддәсендә билгеләнгән даими булмаган тариф буенча даими рәвештә пассажирларны һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру буенча муниципальара маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга булган таләпләрне бер ел дәвамында кабат бозу.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкче** **Р. В. Михеев**